КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 18

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 07 декабрь, 944 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 7 декабрь, 944 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру кагыйдәләренә, 4 пунктны түбәендәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Оешмаларның стипендия фонды күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = (А_{ср1} \times К_{ср1} + А_{во1} \times К_{во1} + А_{асп1} \times К_{асп1} + А_{раб1} \times К_{раб1} + А_{нпк1} \times К_{нпк1}) \times$$
$$\times 8 + (А_{ср2} \times К_{ср2} + А_{во2} \times К_{во2} + А_{асп2} \times К_{асп2} + А_{раб2} \times К_{раб2} + А_{нпк2} \times К_{нпк2}) \times 4,$$

монда:

С – оешманың стипендия фонды күләме;

$А_{ср1}$ - һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем

алучы студентларына, һөнәри белем бирү оешмаларының урта гомуми белем бирү базасында көндезге формада квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның гыйнвардан алып августка кадәр билгеләнгән нормативы;

$А_{ср2}$ - һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына; һөнәри белем бирү оешмаларының урта гомуми белем бирү базасында көндезге формада квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның сентябрьдән алып декабрьгә кадәр билгеләнгән нормативы;

$К_{ср1}$ – күрсәтелгән мәгариф оешмаларында гыйнвардан алып августка кадәр чорга социаль стипендия алуга хокукы булган урта звено белгечләрен көндезге бүлектә әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән белем алучылар, урта гомуми белем бирү базасында көндезге бүлектә квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары студентлары саны;

$К_{ср2}$ – күрсәтелгән мәгариф оешмаларында сентябрьдән алып декабрьгә кадәр чорга социаль стипендия алуга хокукы булган урта звено белгечләрен көндезге бүлектә әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән белем алучылар, урта гомуми белем бирү базасында көндезге бүлектә квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары студентлары саны;

$А_{во1}$ - югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның гыйнвардан алып августка кадәр билгеләнгән нормативы;

$А_{во2}$ - югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның сентябрьдән алып декабрьгә кадәр билгеләнгән нормативы;

$К_{во1}$ - Татарстан Республикасы бюджеты хисабына бакалавриат, специалитет, магистратура программалары буенча югары белем бирү оешмаларында көндезге бүлектә укучылар һәм гыйнвардан алып августка кадәр чорда социаль стипендия алу хокукына ия булган әлеге белем бирү оешмаларында укучылар саны;

$К_{во2}$ - Татарстан Республикасы бюджеты хисабына бакалавриат, специалитет, магистратура программалары буенча югары белем бирү оешмаларында көндезге бүлектә укучылар һәм сентябрьдән алып декабрьгә кадәр чорда социаль стипендия алу хокукына ия булган әлеге белем бирү оешмаларында укучылар саны;

$А_{асп1}$ - югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү, ординатура, ассистентура-стажировка программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына, ординаторларына, ассистент-стажерларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның гыйнвардан алып августка кадәр билгеләнгән нормативы;

$А_{асп2}$ - югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү, ординатура, ассистентура-стажировка программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына, ординаторларына, ассистент-стажерларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның сентябрьдән алып декабрьгә кадәр билгеләнгән нормативы;

$К_{асп1}$ - гыйнвардан алып августка кадәр чорда фәнни-педагогик кадрлар әзерләү, ординатура, ассистентура-стажировка программалары буенча югары белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты хисабына көндезге бүлектә укучылар саны;

$К_{асп2}$ - сентябрьдән алып декабрьгә кадәр чорда фәнни-педагогик кадрлар әзерләү, ординатура, ассистентура-стажировка программалары буенча югары белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты хисабына көндезге бүлектә укучылар саны;

$А_{раб1}$ - һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның гыйнвардан алып августка кадәр билгеләнгән нормативы;

$А_{раб2}$ - һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның сентябрьдән алып декабрьгә кадәр билгеләнгән нормативы;

$К_{раб1}$ – Татарстан Республикасы бюджеты хисабына төп гомуми белем базасында көндезге уку формасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучылар саны һәм гыйнвардан алып августка кадәр чорда

күрсәтелгән белем бирү оешмаларында социаль стипендия алу хокукына ия булган укучылар саны;

$К_{раб2}$ – Татарстан Республикасы бюджеты хисабына төп гомуми белем базасында көндезге уку формасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучылар саны һәм сентябрьдән алып декабрьгә кадәр чорда күрсәтелгән белем бирү оешмаларында социаль стипендия алу хокукына ия булган укучылар саны;

$А_{нпк1}$ - фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләренең көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның гыйнвардан алып августка кадәр билгеләнгән нормативы;

$А_{нпк2}$ - фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләренең көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыруның сентябрьдән алып декабрьгә кадәр билгеләнгән нормативы;

$К_{нпк1}$ – Татарстан Республикасы бюджеты хисабына көндезге уку формасында гыйльми тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләрендә гыйльми-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча гыйнвардан алып августка кадәр чорда укучылар саны;

$К_{нпк2}$ – Татарстан Республикасы бюджеты хисабына көндезге уку формасында гыйльми тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләрендә гыйльми-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча сентябрьдән алып декабрьгә кадәр чорда укучылар саны;

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин